| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеменең һәм Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме турында» 2012 елның 2 июнендәге ПУ-415 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1055 номерлы, 2015 елның 27 ноябрендәге ПУ-1130 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы һәм 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме турында нигезләмәдә:

9 пунктта «Татарстан Республикасы прокуратурасы,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы,», «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы,» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның икенче абзацында «өч көн вакыт» сүзләрен «10 көн вакыт» сүзләренә алмаштырырга;

б) Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме (алга таба – эксперт төркеме) составында:

эксперт төркеме составыннан М.Г. Әхмәтовны, Р.В. Гыйльмановны, Т.Д. Нагумановны, П.М. Николаевны, И.Ә. Фәйзуллинны, А.А. Фоминны, А.К. Хамаевны чыгарырга;

эксперт төркеме составына кертергә:

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Җәббаров Марат Азат улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрын;

Липский Валерий Андреевичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Соколов Алексей Владимировичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгын (килешү буенча);

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

эксперт төркеме әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ф.С. Габделганиевның – «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Г.И. Сергееваның – «Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы иҗтимагый советының административ һәм гражданлык юнәлешләре буенча рәистәше (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы һәм 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан К.Ф. Әмировны, А.Р. Зариповны, П.М. Николаевны, Р.З. Тимерҗановны, А.А. Фоминны, А.Р. Хәйруллинны, Д.Г. Хәмитовны, В.В. Шихобаловны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Абросимова Алла Владиславовнаны – Татарстан Республикасының яшьләр хөкүмәте рәисен (килешү буенча);

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Демидов Виктор Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Җәббаров Марат Азат улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрын;

Кондратьева Алла Андреевнаны – «Татарстан Республикасы иҗат яшьләре академиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

Липский Валерий Андреевичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Нагуманов Тимур Дмитриевичны – «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгын (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Хвостиков Игорь Владимировичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ф.С. Габделганиевның – «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Г.И. Сергееваның – «Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы иҗтимагый советының административ һәм гражданлык юнәлешләре буенча рәистәше (килешү буенча)».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 02 май
№ ПУ-266